Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Анатыш авыл җирлеге Советы

**КАРАР № XIV-1**

Анатыш авылы 2021 елның 16 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Советының 2014 елның 8 октябрендәге “Җир салымы турында”гы VII-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Советының 2014 елның 8 октябрендәге “Җир салымы турында”гы VII-1 номерлы” карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлеге Советының 2014 елның 5 ноябрендәге VIII-1 номерлы, 2015 елның 28 маендагы VIII-2 номерлы, 2017 елның 22 августындагы VI-1 номерлы, 2019 елның 13 июнедәге IV-1 номерлы, 2020 елның 5 февралендәге II-1 номерлы, 2021 елның 7 декабрендәге XII-1 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пункттагы «беренче квартал беткәннән соң 15 майдан да соңга калмыйча, икенче квартал – 15 августтан да соңга калмыйча, өченче квартал-15 ноябрьдән дә соңга калмыйча. Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килүче елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә» сүзләрен алып ташларга.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Анатыш авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адрес буенча:

- Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Анатыш авылы, Клуб ур., 17 нче йорт;

-Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Шиланка авылы, Яр буе урамы, 1 нче йорт;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

«Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Анатыш авыл җирлеге башлыгы К. К. Җамалиев